Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2023 елның «14» ноябре № 6

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Сәрдекбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 28 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Сәрдекбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сәрдекбаш авылы, Үзәк урам, 45 адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 28 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Сәрдекбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сәрдекбаш авылы, Үзәк урам, 45 адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Сәрдекбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан; 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокл хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү: янгын гидрантларын урнаштыру, янгын сүндерү инвентаре сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган машинаны карап тоту, янгын сүндерү техникасын тоту чыгымнары; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

- Сәрдекбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту;
- Сәрдекбаш авылында зират җиһазлары һәм инвентарьлары сатып алу, зиратны карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- видеокүзәтү сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту;
- Сәрдекбаш авылында урамнарны яктыртуны карап тору; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сәрдекбаш авылы территориясен төзекләндерүне оештыру; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сәрдекбаш авылына балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сәрдекбаш авылында су башнясын ремонтлау һәм карап тоту, артезиан скважинасы өчен насос сатып алу; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
-Сардекбаш авылы чишмәсен ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- ял зоналарын , спорт һәм балалар өчен уен мәйданчыкларын, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен адаптив физик культура һәм адаптив спорт белән шөгыльләнү мәйданчыкларын булдыру, төзекләндерү һәм карап тоту; проект - смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
-Сардекбаш авылы мәдәният йортын ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Сардекбаш авылында юлларга асфальт җәю, ремонтлау, вак таш җәю, юлларны карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Сәрдекбаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сардекбаш авыл җирлеге башлыгы: И.М. Нәбиев

ОГРН 1021607752858
ИНН 1623001854